

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ»

## КУЛЪЯЗМАЛАРЫ

«МИЛЛИ КИТАП»

**ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ**

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ»

ПОЭМАСЫНЫҢ
ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘ
САКЛАНА ТОРГАН КУЛЪЯЗМАЛАРЫНА
ТАСВИРЛАМАЛАР

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2009

УДК 902/904 + 821.0
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)
К 90

*Кулъязмаларны тасвирлаучы*
*һәм кереш мәкалә авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

«КЫЙССАИ ЙОСЫФ» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмаларына тасвирламалар / төз.-авт.
К 90 Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 92 б. –
(«Татар археографиясе» сериясе; 3 нче китап).
ISBN 978-5-88473-051-9

Бу китапта борынгы язма әдәбиятыбыз ядкәре – мәшһүр шагыйрь Кол Гали иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган, XVII–XX гасырларга караган 33 берәмлек кулъязма күчермәсенең тасвирламалары тәкъдим ителә.

УДК 902/904 + 821.0
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)

ISBN 978-5-88473-051-9

© Мәрданов Р.Ф., 2009
© «Милли китап» нәшрияты, 2009

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ПОЭМАСЫНЫҢ ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘГЕ КУЛЪЯЗМА НӨСХӘЛӘРЕ

Мәшһүр шагыйрь Кол Гали XIII гасыр башында иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәре хаклы һәм лаеклы рәвештә милли әдәбиятыбызның чишмә башы дип санала.

Идел-Урал буйларында яшәгән татарлар дини сюжетка нигезләнгән «Кыйссаи Йосыф»ны гасырлар дәвамында укып, әсәр геройлары белән бергә хәсрәтләнгәннәр һәм куанганнар, юаныч һәм гыйбрәт-сабак алганнар. Бөек әсәрнең сихри һәм шигъри куәте үзеннән соңгы татар һәм, гомумән, төрки телләрдәге тугандаш халыклар әдәбиятының үсешенә гаҗәеп зур йогынты ясаган.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы элек-электән әдипләрнең һәм галимнәрнең игътибарын җәлеп иткән. Аның тәэсирендә һәм аңа ияреп бихисап шигъри әсәрләр иҗат ителгән, аның турында байтак фәнни хезмәтләр, китаплар һәм мәкаләләр язылган. Поэманың 1983 елда Татарстан китап нәшриятында зур форматта, 544 бит күләмендә басылып чыгуы[1] – милли-мәдәни тарихыбызның XX гасырдагы иң зур вакыйгаларыннан берсе булды. Мәртәбәле бу китапта поэманың тулы төп тексты (транскрипциясе), хәзерге татар әдәби теленә шигъри күчерелмәсе һәм рус теленә сүзгә-сүз тәрҗемәсе, шулай ук бай фәнни белешмә мәгълүмат тупланган. Әлеге олуг хезмәтне галим, ул вакыттагы СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Фазыл Фәсиев башкарган. Фазыл аганың сокландыргыч тырышлык нәтиҗәсе замандашларыбызга, шулай ук киләчәк буын-

[1] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе) / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – 544 б.

нарның тел-әдәбият галимнәренә, текстолог һәм археографларына фидакяр иҗади хезмәт үрнәге булып тора.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы моңарчы дөнья күргән китапларда һәм фәнни хезмәтләрдә тирәнтен өйрәнелгәнлектән, без аңа кагылып тормыйча, әсәрне гасырдан-гасырга, буыннан-буынга ирештергән төп чыганаклары – кульъязма күчермәләренә тукталабыз.

1980 елда фәнгә «Кыйссаи Йосыф» әсәренең, нигездә, Идел-Урал җирлегендә күчерелгән 161 нөсхә кульъязмасы мәгълүм иде[2].

Археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә әсәрнең кульъязма нөсхәләре елдан-ел табылып тора. 1980–1998 еллар арасында «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең табылуы һәм аларның гомуми исәбе турында мәгълүматлар туплап язган идек[3]. Ягъни, 1986–1991 елларда Казан дәүләт университетының Горький өлкәсендә эшләгән фәнни-археографик экспедицияләрендә поэманың утызга якын кульъязмасы табылуын, Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре тарафыннан да 1980 елдан соң унбишләп яңа табыш өстәлгәнен һәм 1992–1998 елларда Татарстан Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе эшчәнлеге нәтиҗәсендә мәшһүр әсәрнең тагын 15 нөсхә күчермәсе табылганын исәпкә алып, 1998 елда «Кыйссаи Йосыф» кульъязмасының фәнни даирәләргә барлыгы 220 тирәсе күчерелмәсе билгеле дип белдергән идек[4]. Поэманы өйрәнгән әдәбият галимнәре дә ул елларда «Кыйссаи Йосыф»ның 200 дән артык күчермәсе бар дип яздылар[5]. Әлеге саннар «Кыйссаи Йосыф» кульъязмаларының һаман да табылып, гыйльми оешмаларга тупланып килүен күрсәтә.

Йосыф китабы күчермәләренең исәбен аныклап белдергән 1998 елдан соң да ун ел вакыт үтте. Әсәрнең галимнәргә билгесез кала килгән күчерелмәләре, шушы вакыт эчендә дә, әлбәттә, табыла торды. Бу мәкаләдә хәзерге көндә фәнни оешмаларда, китапханә-

---

[2] Шунда ук. – Б. 490.

[3] Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 25; Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

[4] Шунда ук.

[5] Хисамов Н. Поэма «Кисса-и Йусуф» Кул ’Али // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: Фэн, 1999. – С. 50.

ләрдә һәм музейларда «Кыйссаи Йосыф» поэмасының ничә күчермә нөсхәсе саклануын барлап, төгәл санын ачыклауны максат итеп куймадык. Тик, шулай да, фәнгә билгеле кулъязмаларының якынча 270 тирәсе булуын чамаларга мөмкин.

***

Мәшһүр әсәрнең бу китапта тасвирлана торган нөсхәләренә киңрәк тукталыйк.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы кулъязмаларының иң беренчесе Татарстан Милли китапханәсенә 1991 елның июнь аенда Ютазы районының Бәйрәкә авылыннан алынган иде. 1992 елда китапханәгә әсәрнең тагын ике күчермә нөсхәсе керде. Аннан соңгы елларда табышлар түбәндәгечә булды:

1993 елда – 3 кулъязма;
1994 елда – 2 кулъязма;
1995 елда – 4 кулъязма;
1996 елда – 9 кулъязма;
1997 елда – 1 кулъязма;
1998 елда – 2 кулъязма;
2000 елда – 2 кулъязма;
2001 елда – 1 кулъязма;
2002 елда – 2 кулъязма;
2005 елда – 1 кулъязма;
2006 елда – 1 кулъязма;
2008 елда – 2 кулъязма.

Шулай итеп, хәзерге вакытка, ягъни 2008 елның ахырына, Республиканың Милли китапханәсендәге «Кыйссаи Йосыф» кулъязмалары 33 нөсхәне тәшкил итә. Болардан 15 берәмлек кулъязма китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәрләренең аерым археографик сәфәрләрендәге һәм Казан шәһәрендәге эзләнүләре нәтиҗәсендә тупландылар, ә 11 берәмлек Татарстан Милли китапханәсе белән Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясендә табылган, 4 берәмлек китапханәгә бүләк итеп бирелгән һәм 3 берәмлек сатып алынган. Китапханәдә саклана торган әлеге ядкәрләрнең 17 ел эчендә

(1991–2008) туплануын исәпкә алганда, бу башкарылган эшнең нәтиҗәлелеген күрсәтеп тора.

Кулъязмаларның иң әүвәлге икесе XVII йөз ахырына нисбәтле, дүртесе – XVIII гасырга карый. Иң күбесе – 24 кулъязма берәмлек XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән. Бер кулъязма 1856–1857 елларга карый. Поэманың 1950 нче һәм 1960 нчы еллардагы соңгы дәвер күчермәләре үлемсез әсәрнең күп гасырлык язма традициясе дәвамлылыгына дәлил буларак әһәмиятле.

Китапханәдә тупланган «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең табылу географиясе дә шактый киң. Шулардан Казан шәһәрендә – унбер, Татарстанның Арча районыннан – ике, Апас, Әгерҗе, Теләче, Ютазы районнарыннан – берешәр, Уфа шәһәреннән – өч, Башкортстанның Тәтешле районыннан – ике, Пермь өлкәсенең Барда районыннан – өч, Мари Эль Республикасының Бәрәңге районыннан – бер, Чуашстанның Комсомольск районыннан – бер, Пенза өлкәсенең Городище, Каменка, Кузнецк һәм Неверкино районнарыннан (һәрберсеннән берәр) – дүрт, Самара өлкәсенең Шонталы районыннан – бер, Тобольск каласыннан – бер кулъязма табылган. Монда Казан табышлары арасында исәпләнгән, М.Садри китапханәгә бүләк иткән кулъязманың 1940 нчы елда Омск өлкәсенең Тәвриз районында табып алынган булуын искәртергә кирәк.

Кулъязмаларның тугызы Казан һәм Уфа шәһәрләрендәге, Самара өлкәсенең Динис авылындагы, Пермь өлкәсенең Барда авылындагы мәчетләрдән табып алынган. Бу уңайдан тел һәм әдәбият галиме Хәсән Галинең (1878–1940) моннан йөз ел чамасы элек үк «бездә мәсҗедләрнең түбәләре, очырмалары бер архива урынын тотып, һәр төрле иске китап вә язулар шуннан табылдыгы мәгълүмдер»[6] дип, бик хаклы язган сүзләре хәтергә килә. Милли китапханәгә тупланган кулъязма мирасның да аерым бер өлеше шәһәрләр һәм авылларның мәчетләрендә һәм аларның чормаларында электән җыелып килгән байлыктан гыйбарәт. Мәчетләрдән табылып алынган «Кыйссаи Йосыф» күчермәләренең икесе Казан шәһәрендәге «Болгар» мәчетеннән, өчесе «Мәрҗани» мәчетеннән (шулардан берсе – китапханәгә М.Килдиевтән) алынды.

[6] Хәсән Гали. Акмулла шигырьләре хакында // Шура. – 1912. – № 14. – Б. 430.

Китапханәдә саклана торган өч кульязма нөсхәнең шагыйрьләр исеме белән бәйле булуы да кызыклы бер күрсәткеч. Кульязмаларның берсен XIX гасыр шагыйре Гали Чокрый үз кулы белән күчергән булса, икенчесе – шагыйрә Заһидә Бурнашеваның шәхси архивына нисбәтле, ә өченчесен – шагыйрь Мөхәммәт Садри, 55 ел дәвамында күз карасыдай саклаганнан соң, китапханәгә бүләк итеп бирде. Шул рәвешчә, XIII гасырда иҗат ителгән поэма дәверләр кичеп, төрле буын татар шагыйрьләрен үзенә тартып һәм җәлеп итеп торган.

Бу китапта тасвирланган 33 кульязма арасында текстлары тулы диярлек дәрәҗәдәге һәм шактый күләмлеләре (мәсәлән, 404 т, 486 т, 779 т, 1121 т, 2774 т, 2068 т, 2069 т), 4–10 битле өзекләр, шулай ук 1–2 битлек фрагментлар бар. Ләкин берничә битле фрагментлар да әһәмияткә ия. Хәзерге вакытка ялгыз битләре генә сакланып калган булса да, алар кайчандыр кулланылган мөстәкыйль кульязмаларның өлешләре.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы халык арасында шул дәрәҗәдә популярлашкан булган ки, төрле чорларда бу әсәрнең шигъри калыбы һәм үлчәмендә күп санлы бәетләр һәм җырлар иҗат ителгән. Милли китапханәдә андый әсәрләр теркәлгән кульязмалар да саклана. Алар, ихтимал, «Татар археографиясе» сериясенең киләчәктәге чыгарылышларының берсендә туплап бирелерләр.

***

Бу китапта «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган барлык 33 кульязмасы тасвирламалары бирелде. Кульязмалар түбәндәге тәртип буенча тасвирланды:

1) тасвирлау номеры (өстә, уртада);
2) китапханәдәге саклану шифры (өстәге сул почмакта);
3) әсәрнең исеме (гарәп хәрефләре белән язылышы);
4) авторы;
5) әсәр исеме;
6) кәгазенең төре һәм төсе;
7) кәгазьнең филигране (су билгесе);
8) күләме;

9) әсәр текстының тулылыгы;
10) тышлыгы;
11) сакланыш дәрәҗәсе;
12) форматы;
13) бер биттә текст язылган мәйданның зурлыгы;
14) текстның башы һәм ахырындагы юллары, аларның 1983 ел басмасындагы текстның ничәнче битенә туры килүләре;
15) язу карасы;
16) язу төре-почеркы;
17) текстның палеографик үзенчәлекләре;
18) кустодлары;
19) рамкалар;
20) элекке пагинациясе;
21) мөһер һәм штамплар;
22) дефектлары;
23) күчерелгән вакыты;
24) күчерелгән урыны;
25) күчерүчесе;
26) коллофоны;
27) җыентык эчендә булса, башка әсәрләр һәм язмалар турында мәгълүмат;
28) кулъязма хуҗасының язмалары;
29) китапханәгә кайдан, кемнән, кайчан һәм кем тарафыннан алынуы;
30) басылып чыккан мәгълүмат булганда, кыскача библиографик белешмә.

Югарыда әйтелгән үзенчәлекләр (мәсәлән, тышлыгы, рамкалары яки коллофоны) булмаган очракта аларның юклыгы тасвирда күрсәтелмәде.

Кулъязмаларның күпчелегенә хас булган кайбер гомуми күренешләрне тасвирламаларда кабатлап тору кирәксез дип табылды. Мәсәлән, поэманың монда тасвирланган текстлары, берсеннән (№33) башка, һәммәсе дә гарәби язулы шигъри әсәрләр шәкеленчә, бер кәгазь битендә икешәр баганалы итеп язылганнар. Һәр кулъязма нөсхәнең диярлек бит читләрендә төп текстка кагылышлы өстәмә (төшеп калган сүзләр һәм юллар яки хаталы сүзләргә төзәтмә)

язулар бар. Күпчелек нөсхәләрдә аларның күчерелгән урыннары күрсәтелмәсә дә, палеографик үзенчәлекләренә нигезләнеп, Идел-Урал буйларына нисбәтле татар кульязмалары икәнлеге аңлашылып тора. Менә болар тасвирларда бирелмәде.

«Кыйссаи Йосыф» кульязмалары кәгазьләренең форматы һәм бер биттәге текст язылган мәйдан берничә төрле зурлыкта булган очракларда, андыйларының һәр варианты да җәяләр эчендә күрсәтелде.

Берничә битле фрагментлардагы текстларның башындагы һәм ахыргы юллары тасвирда бирелмәде. Ә дүрт биттән артыграк күләмне тәшкил иткән кульязмалар тасвирында алар күрсәтелде. «Кыйссаи Йосыф» әсәренең кульязмалары белән эш иткәндә уңайлы булсын өчен тасвирланган күчермәләрдәге текстның башы һәм ахыры 1983 елгы басма китапта кайсы биткә туры килүләре искәртелде. Әмма текст башы һәм ахыры арасында өзеклекләр, аермалар, үзенчәлекләр дә бар. Мәсәлән, беренче карашка тулы текстлы кебек тоелган, башы һәм ахыры булган, 21 нче номер белән тасвирланган, китапханәдә «486 т» шифры белән саклана торган кульязма, беренчедән, ике аерым кульязма тексттан берләштерелгән булса, икенчедән, тексты эчендә дә җитешмәгән битләре һәм төшеп калган өлешләре бар. Аерым бер кульязманың башындагы һәм ахырындагы юллары 1983 елгы басманың фәләненче битләренә туры килә дип язылган сүз күчереп бирелгән өземтәләрнең басмадагы текстка сүзгә-сүз тәңгәл килүен белдерми. Кульязмалардан алынган текст башындагы һәм ахырындагы шигъри юллар үзләрендә язылганча ук (хаталы булса, шул хәлендә), үзгәртелмичә, хәзерге татар язуына транслитерация рәвешендә күчерелделәр.

Текстларның палеографик үзенчәлекләре буларак күрсәтелгән тәнвиннәр гарәп графикасында кайбер кушымчалардагы һәм сүз ахырларындагы хәрефләрнең *–ан, –ән, –ин, –ун, –үн* рәвешендәге өстәмә тамгалар белән язылышын аңлата. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, төрки тамырлы сүзләрне тәнвиннәр һәм хәрәкәләр кулланып язу – иҗат ителү вакыты борынгырак булган әсәр күчермәләренә хас күренеш. Бу электән килгән палеографик традиция «Кыйссаи Йосыф»ның кульязма нөсхәләрендә еш очрый.

Кулъязмаларның күчерелгән вакытлары үзләрендә булмаган очракта, тасвирламада филиграньдәге елларын күрсәттек. Ә филиграньнәре булмаган кулъязмаларның вакыт нисбәте, язу һәм кәгазь төренә күрә, палеографик үзенчәлекләренә карап һәм эш тәҗрибәбезгә нигезләнеп (гасырның башы яки ахыры, беренче яки икенче чиреге рәвешләрендә) якынча билгеләнде.

Тасвирламалар китапта хронологик тәртип буенча урнаштырылды.

Китапханәдә элеккерәк елларда оештырылган «Кыйссаи Йосыф» кулъязмаларының тематик һәм башка күргәзмәләр уңаеннан язылган, шулай ук китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге эшчәнлеген яктырткан мәкаләләрдә поэманың күчермәләре искә алынган очраклар турында тасвирларда библиографик белешмә бирелде.

Кулъязма тасвирламалары янәшәсендә күчермә-факсимиле үрнәкләре урын алды.

Китап ахырында өстәмә белешмәләр өчен кулъязмаларның тасвирламасында очраган исемнәр һәм географик атамалар күрсәткечләре, шулай ук күчерелү һәм китапханәгә алыну вакытлары күрсәткечләре бирелде.

# ҚЎЛЁЗМАЛАР ТАСВИРЛАМАСИ

1

590 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге европа кәгазендә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Иске кулъязма китап тышлыгы өчен ябыштырылып эшләнгән аерым кәгазь битләренең берсе.

Сакланышы начар.

Форматы: 11 х 14,5.

Язу карасы – кара төстә.

Язу почеркы – бозык нәсех.

Төрки сүзләрне хәрәкәләр белән һәм «син» хәрефенең астына өчәр нокта куеп язылган палеографик үзенчәлекләргә ия.

Күчерелгән вакыты – XVII гасыр ахыры.

Казан шәһәренең «Болгар» мәчетеннән китапханә хезмәткәрләре Ирек Һадиев һәм Раиф Мәрданов тарафыннан 1993 елның май аенда алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 25–26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

4. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).



*«590 т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

## 2

591 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге европа кәгазендә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Иске кулъязма китап тышлыгы өчен ябыштырылып эшләнгән аерым кәгазь битләренең берсе. Һәр битендә икешәр баганага бүлеп язылган текстның бер баганасы гына тулаем, икенчесенең берничәшәр хәрефе генә күренә.

Сакланышы начар.

Форматы: 8,5 х 15.

Язу карасы – кара төстә.

Язу почеркы – нәсех.

Текстта «син» хәрефенең астына өчәр нокта куеп, төрки сүзләрне хәрәкәләр белән һәм тәнвиннәр кулланып язылган палеографик үзенчәлекләргә ия. Мәсәлән, «кыйлс(ун)» рәвешендә. «Имди» сүзе «эмди» рәвешендә генә, ягъни сүз башындагы «йа» хәрефеннән башка язылган.

Күчерелгән вакыты – XVII гасыр ахыры.

Казан шәһәренең «Болгар» мәчетеннән китапханә хезмәткәрләре И.Һадиев һәм Р.Мәрданов тарафыннан 1993 елның май аенда алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 25–26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

4. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).



*«591 т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

3

1401 т

# قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Сакланышы уртача.

Ак төстәге европа кәгазендә.

Форматы: 15 x 18,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,3 (12) x 14 (15,5).

Язу карасы – саргылт-көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Берничә сүздә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр (мәсәлән, «с(ән)» рәвешендә).

Кәгазе бер урында тишелгән һәм язуы өлешчә уңган.

Күчерелгән вакыты – XVIII гасыр башы.

Татарстанның Арча районы Яңа Кишет авылында яшәүче Фәйрүзә Шәрәфиевадан 1996 елның августында китапханә хезмәткәре Айрат Заһидуллин тарафыннан алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.




*«1401 т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

4

1228 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге европа кәгазендә язылган. Филиграньнәре бар.

Күләме: 60 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача. Төбе калын җеп белән тегелгән.

Форматы: 16,8 х 20,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10,5 (11) х 16 (16,5).

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Йосыф әйдүр: «Йа, къәрдәшләр, бәңа къилмаң,*
*Шәйтан сүзенә гөмраһ къилыб, аңа уймаң.*

Текстның ахыры (60б кәгазьдә):

*Бәшир адлу кечек угълум сатмышиде,*
*Йитмеш йылдур хәсрәтен тартарым имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 71 битендәге, ә ахыры 270 битендәге текстка туры килә.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Язу карасы – тексты сыек көрән, фасыл исемнәре кызыл төстә. 59б кәгазендә аерым юлы кызыл белән язылган.

Язу почеркы – татар тәгъликы. Кайбер урыннарда сөлес һәм шикәстә язулары элементлары бар.

Текстта, сирәк булса да, хәрәкәләр һәм тәнвиннәр куелган. Мәсәлән, 2а кәгазьдә «койуд(ан)», «хатеренд(ән)», 51б кәгазьдә «кәлс(үн)», «улс(ун)» рәвешендә.

Кулъязма юешләнү кичергән. Кайбер битләрендә (мәсәлән, 22–28, 38–39 кәгазьләрдә) язуының карасы коелып, тоныкланган. 37 нче кәгазе аеруча таушалган, читләре ертылган. 48б кәгазьдә язылган берничә юл өстеннән кызыл кара белән сызылган.

Күчерелү вакыты – кәгазьдәге су билгеләре 1751–1756 елларга карый.

Кулъязма соңгы хуҗаларына Башкортстанның Чишмә районындагы Сәйран авылында яшәгән Нәбиулла Сәйфуллиннан (1943 елда вафат) калган.

Уфа шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Нурдидә Биктимерова 1996 елның 11 декабрендә китапханәгә бүләк итеп биргән.



*«1228 т» шифрлы кулъязма. 18а кәгазь.*

## 5

2069 т **قصهٔ یوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ачык яшькелт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 63 кәгазьдә. Башы юк.

Сакланышы уртача. Башындагы һәм ахырдагы битләре тегелгән җебеннән аерылган.

Форматы: 15,5 х 24.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 9,5 х 14,5.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ул угъланны кәм бәһайә сат(ун) алгыйл, –*
*Тәлим мал бәһайә сатгыйл имди.*

Текстның ахыры (63б кәгазьдә):

*Бу китабны бу арада тәмам къилдым,*
*Вә нәгъәсна вә әййакәр кыйла имди.*

Бу кульъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 90 битендәге, ә ахыры 294 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – төп тексты көрән, фасыл исемнәре кызыл төстә.

Язу почеркы – бозыграк нәсех, берничә биттә татар тәгъликы (мәсәлән, 1а, 1б, 24б, 59б кәгазьләр).

Текстта төрки сүзләрдә хәрәкәләр куеп һәм тәнвиннәр кулланып язу кебек палеографик үзенчәлекләр күзәтелә. Тәнвиннәр, мәсәлән, 1а кәгазьдә «сат(ун)», 5а кәгазьдә «бәнд(ән)», «сүз(ин)», 15б кәгазьдә «алтунд(ан) улс(ун)» рәвешендә.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Кульъязманың 2–3 һәм 9 нчы кәгазьләре реставрацияләнгән. 19б кәгазе дефектлы. 23а һәм 45б кәгазьләрдәге фасыл исемнәренең язуы бозылган. Иң ахырдагы 63 нче кәгазе таушалган, язуы начар укыла.

Филиграньдә еллары «1791» һәм «1795», коллофонда 179? – соңгы саны укылмый.

Күчерелгән урыны – Олуг Кавал авылы.

Күчерүчесе – 25а кәгазьдә «кәтәбәһе Сәедкол» диелгән, коллофондагы исем укылмый.

Коллофоны (63б кәгазьдә): «Буны йаздым... Бу китаб Йосыфның ... тарих мең дә йите йөз тукса[н] ... айында, йекерме бишенче көнендә йазылды. Дүшәнбә көн иде. Бу китаб Олуг Кавалның Котлы...».

Китапханәгә 2008 елның декабрь аенда Казан шәһәрендә сатып алынган.



*«2069 т» шифрлы кульязма. 14б кәгазь.*

## 6

1402 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Иске кулъязма китапка тышлык өчен ябыштырылып эшләнгән аерым кәгазь битләренең берсе.

Сакланышы начар.

Ак төстәге рус кәгазендә.

Форматы: 14,5 x 19.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12,5 x 15,5.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Кәгазе таушалган. Бит читендә язуы начар таныла.

Күчерелгән вакыты – XVIII гасыр ахыры.

Татарстанның Арча районы Яңа Кишет авылында яшәүче Фәйрүзә Шәрәфиевадан 1996 елның августында китапханә хезмәткәре А.Заһидуллин тарафыннан алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.



*«1402 т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

## 7

1763т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 52 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Тышлыгы – күн белән тышланган катыргы. Өстеннән зәңгәр төстәге киндер тукыма белән тышланган.

Сакланышы уртача. Башындагы һәм уртадагы аерым битләре тегелгән җебеннән аерылган.

Форматы: 17 (17,5) х 22.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10,5 (11) х 15,5.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Әулийа вә әткъийа һөммәи динларә,*
*Җөмләсен дә Халикъ разый улсун имди.*
*[Йа,] Мөхәммәд, бу дөшне Йосыф күрде,*
*Ай-күн, бер улдуз сәҗдә кыйлды.*

Болардан беренче бәйт әсәрнең 1983 елгы басмасында юк, ә икенче бәйте 1983 ел басмасында 424 биттә.

Текстның ахыры (52а кәгазьдә):

*Һәр каныксы сү деләсә сәфә вирде,*
*Мотабәгат кыйлмаклыга тәшриф күрде.*

Бу кулъязмадагы текстның ахыры әсәрнең шул ук басмасындагы 224 биттәге текстка туры килә.

Язу карасы – төп тексты һәм 44б кәгазьдәге фасыл исеме көрән, ә башка фасыл исемнәре кызыл төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Текстта төрки сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр куелган урыннары бар. Тәнвиннәр, мәсәлән, 1а кәгазьдә «бер(ин)-бер(ин)», 22б кәгазьдә «Халикъд(ан)» һәм «гөнаһлар(ин)», 23а кәгазьдә «сәбәбд(ән)» рәвешендә. «Уау» хәрефе өстенә өчәр нокта куелган.

Кустодлары бар, тотрыклы. Кайбер битләрдәге кустодлар көрән (48б кәгазьдә кызыл) төстәге гади бизәк-кыса эченә алынган.

Кулъязманың 1 нче кәгазе урталай ертылган һәм җеп белән тегелгән. 1–2 кәгазьләрнең төп яклары таушалган. Кайбер битләре

(мәсәлән, 46б–47а кәгазьләр) шәмәхә төстәге карага буялган. 11 нче кәгазе үтәли тишелеп ертылган. 38 нче кәгазьнең уртасы ертылган.

Филиграньдә елы «1801».

Күчерүчесе – Шәрифулла, дусты Габделгалләм өчен.

Кулъязманың 18а кәгазендә «Шәрифулла ли-әҗли дустым Габделгалләм дәйү беләсезләр» дигән юллар язылган.

Татарстанның Теләче районы Урта Мишә авылында яшәүче Гөлбикә Нәбиуллинадан 1996 елның августында китапханә хезмәткәре А.Заһидуллин тарафыннан алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.



*«1763 т» шифрлы кулъязма. 38а кәгазь.*

## 8

1121 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Яшькелт-зәңгәр төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: кулъязма җыентыкның 14б–89б кәгазьләрендә (барлыгы 76 кәгазьдә). Ахыры юк.

Сакланышы уртача. Төбе җеп белән тегелгән. 84–85 нче кәгазьләре җептән аерылган, башка берничә бите җебенә начар эләгеп тора.

Форматы: 16,2 х 19,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 х 16.

Текстның башы (14б кәгазьдә):

*Әлхәмдү шөкер сипас ул Әхәдә,*
*Мөлке би зәваль ул Самәдә.*

Текстның ахыры (89б кәгазьдә):

*Каил, самигъ бу мөзнибә дога кыйлса,*
*Мөҗиб доганы мөстәҗаб къилур имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 46 битендәге, ә ахыры 292 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – текст ачык һәм караңгы көрән, ә фасыл исемнәре кызыл төстә. Кайбер гадәти бәйт-юллар да (мәсәлән, 37б кәгазьдә) кызыл төстәге кара белән язылган.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Текст 83б кәгазьдә көрән төстәге кара белән бер сызыклы, 84а–89б кәгазьләрдә кызыл төстәге икешәр сызыклы рамка-кысага алынган.

Кулъязманың битләре, бер кат сүтелгәннән соң, өстәмә кәгазьләр ябыштырып яңадан төпләнгән.

Текст «уау» хәрефе өстенә өчәр нокта куеп һәм тәнвиннәр кулланып язылган палеографик үзенчәлекләргә ия. Тәнвиннәр, мәсәлән, 15б кәгазьдә «хатеремд(ән)» һәм 69б кәгазьдә «хәл(ин)» рәвешендә.

Филиграньдә еллары «1803» һәм «1804».

Кулъязманың 1а–14а кәгазьләрендә Ислам дине нигезләре һәм намаз тәртипләренә багышланган текст язылган.

Казан шәһәренең «Мәрҗани» мәчетеннән 1996 елның 26 мартында китапханә хезмәткәрләре Р.Мәрданов һәм И.Һадиев тарафыннан алынган.



*«1121 т» шифрлы кулъязма. 88а кәгазь.*

9

1400 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ачык зәңгәр рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 10 кәгазьдә. Арада 7а дип бит саны куелган өстәмә кәгазе бар. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача.

Форматы: 16 х 21.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 13 (13,5) х 17,5 (18).

Текстның башы (1б кәгазьдә):

*Кызыл алтун тасы афтәб әленә вирде,*
*Күтәрүб(ән) ул мәҗлесә илтүр имди.*

Текстның ахыры (9б кәгазьдә):

*Һәйбәтендән дошманлар тетрәшерләр,*
*Васфын күрән җөмлә хәйран калур имди.*

Бу кульязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 174 битендәге, ә ахыры 207 битендәге текстка туры килә.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Текстның берничә урынында аерым сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр куелган. Мәсәлән, 1б кәгазьдә күтәрүб(ән).

Бит читләре тузган, язуы уңган.

Филиграньдәге елы «1814».

Кульязманың 1а кәгазендә: «Ильяс, Таҗетдин, Юныс, Мөхәррәм», «Габделвахид Габделкәрим угылы» һәм «Габдеррафигъ Габделвахид угылы» дигән кеше исемнәре язылган.

Уфа шәһәрендә Россия, Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең Европа илләре мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте мәчете чормасыннан 1998 елның март аенда китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан алынган.



*«1400 т» шифрлы кулъязма. 7б кәгазь.*

## 10

1859 т قصهٔ یوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 73 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача. Җеп белән тегелгән төбеннән дәфтәрләре аерылган. Башындагы ике кәгазе җебеннән аерылган.

Форматы: 16,7 (17) х 21,4.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 х 15,5 (16).

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Мәшһүрдүр айәтдә ул Җәббардан,*
*Бер җәһүд вар иде, ады Бустан.*

Текстның ахыры (73б кәгазьдә):

*Йосыф бер кол сәтун алды Бәшир атлу,*
*(Ошпу сүзе дыңламага йаулакъ датлу).*

Бу кульязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 424 битендәге, ә ахыры 270 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – төп тексты көрән, ә фасыл исемнәре кызыл төстә. Кайбер аерым юллар да (мәсәлән, 40а, 41а, 44б, 63а кәгазьләр) кызыл белән язылган.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Текстта «уау» хәрефе өстенә өчәр нокта куелган, төрки сүзләрдә хәрәкәләр һәм тәнвиннәр куелган урыннары бар. Тәнвиннәр, мәсәлән, 2б кәгазьдә «безд(ән)», 4б кәгазьдә «шәфкъәт(ин)», 48б кәгазьдә «гъилм(ин)», 73б кәгазьдә «оҗмахд(ан)» рәвешендә.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Текст 1–2, 13а, 31б кәгазьләрдә кызыл төстәге кара белән, ә 3–10 кәгазьләрдә сыек яшел төстәге кара белән сызылган рамкага алынган.

Кульязманың төбе юешләнү кичергән. 1 нче кәгазе бик таушалган. Пычрак һәм таплы битләре бар.

Филиграньдәге еллары «1813» һәм «1815».

Күчерүчесе – Габдулла ибне Дауд ибне Ишм[өхәммәд] ибне Динмө[хәммәд] ибне Бикмөхәммәд ибне Кодаш.

Кульъязманың кайбер бит читләрендә төп тексттан соңрак карандаш белән язылган хаталы сүзләр һәм гыйбарәләр, җыр юллары бар. Мәсәлән, 48б кәгазьдә:

1) «Базарлардан алыб кайт ике битле (?) гөл...»;

2) «Өзелеб уйлар уйлаганда дәртле күңлем йугала».

57б кәгазьдә: «Миңнезакир Кәмаледдинев угылына чыкмыш».

Самара өлкәсенең Шонталы районы Динис авылы мәчетеннән 1997 елның 14 августында китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан алынган.

Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).



*«1859 т» шифрлы кульъязма. 33а кәгазь.*

11

1774 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 56 кәгазьдә. Арада 14а дип бит саны куелган өстәмә кәгазе бар. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача. Кайбер битләре тегелгән җебеннән аерылган.

Форматы: 16 х 21,4.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10 (10,5) х 15.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Къиссалардан, хикмәтләрдән күрклүрәге,*
*Усанмадан дыңламага датлуракы.*

Текстның ахыры (55б кәгазьдә):

*[Нәкыль къилд]ы, Халикъга улды васләт,*
*Әрхәм аңа рәхмәт нисар къилды имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 50 битендәге, ә ахыры 288 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – төп тексты һәм кайбер фасыл исемнәре (мәсәлән, 5б, 7б, 23а кәгазьләрдә) көрән, фасыл исемнәре кызыл төстә.

Язу почеркы – бозык нәсех.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Текст 11б–12а, 22а, 41 кәгазьләрдә карандаш белән рамкага алынган. 12б–14а кәгазьләрдә ике багана итеп язылган текстның юл ахырларында түгәрәк бизәк-рәсемнәр ясалган.

Кулъязманың 18а–48а кәгазьләрендә гарәп саннары белән язылган пагинация сакланган (26–60 саннары).

Кулъязма төбе, ягыннан юешләнгән булу сәбәпле, саргайган. Кайбер битләре һәм аерым юллары пычрак һәм таплы. 1–4 кәгазьләрнең түбәнге яртышар өлешләре юк, 5–6 һәм 19 кәгазьләр урталай ертылган. 50–55 кәгазьләрнең читләре, аеруча таушалганга күрә, кисеп алынган.

Филиграньдәге елы «1815».

Күчерүчесе – Габделҗәббар Габделмәннаф угылы.

Кульязма хуҗасының язмалары (көрән төстәге кара белән):

16а кәгазьдә «Минем никахым җомга көн, җомгадин соң булды»;

17а кәгазьдә «Йосыф китабы Габделҗәббарныкы, үзе язды»;

18а кәгазьдә «Минем үземнең «Йосыф китабы», йәнә «Раунакыль-ислам» китабы, йәнә «Сөбате гаҗизин» китабы, йәнә «Фәзали шөһүр» китабы, йәнә «Әмалый» китабы, «Мокаддимәт» китабы, йәнә «Чупан» китабы, йәнә «Устуани» китабы, йәнә»;

30б һәм 31б кәгазьләрдә карандаш белән хат башламнары язылган;

32а кәгазьдә шәмәхә төстәге кара белән латин язуында «Гъәптрәхмәнова Зарифа»;

36а кәгазьдә көрән кара белән гарәп язуында «Ошбу китабны укыгучы Фатыйма»;

43б кәгазьдә карандаш белән «Ошбу китаб Габделҗәббар бине Габделмәннаф угылы – йазгучы. Укыгучы – Габделҗәббар кызы Бибифатыйма».

Уфа шәһәрендә Россия, Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең Европа илләре мөселманнарының Үзәк дини нәзарәте мәчете чормасыннан 1998 елның март аенда китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан алынган.



*«1774 т» шифрлы кульязма. 34б кәгазь.*

## 12

2070 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Зәңгәрсу-яшькелт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 20 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача. Төбе җеп белән тегелгән.

Форматы: 17 х 22.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12,5 х 15.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Ул дәмд[ә] шидтәтләр китде, райут улды,*
*Мисыр эчр[ә] Йосыф улу мәлик улды.*

Текстның ахыры (20б кәгазьдә):

*Әһле сәтер, къәум, хәсъм къәрдашләре,*
*Дүгәл ишә кадыйрдур изем вари.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 210 битендәге, ә ахыры 274 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – кара төстә.

Язу почеркы – гадәти татар тәгъликы.

Текстта төрки сүзләрдә хәрәкәләр (мәсәлән, 11б кәгазьнең соңгы юлы) һәм тәнвиннәр куелган урыннары бар. Тәнвиннәр, мәсәлән, 10а кәгазьдә «койуд(ан)», 15а кәгазьдә «сезд(ән) рәвешендә.

Кустодлары гади бизәк-рамка эченә алынган, тотрыклы.

Кулъязманың 1а кәгазендә язуы тоныкланган, начар укыла. Кулъязма элек юешләнү кичергән.

Филиграньдә елы «1821».

Китапханәгә 2008 елның декабрь аенда Казан шәһәрендә сатып алынган.



*«2070 т» шифрлы кулъязма. 12б кәгазь.*

13

1030 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге европа кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 2 кәгазьдәге фрагмент.

Сакланышы начар.

Форматы: 16 x 22,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10 x 18.

Язу карасы – ачык көрән.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

1 нче кәгазе урталай ертылган, ә 2 нче кәгазьнең ярты (түбәнге) өлеше генә сакланган.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Казан шәһәренең «Мәрҗани» мәчетеннән 1996 елның 26 мартында китапханә хезмәткәрләре Р.Мәрданов һәм И.Һадиев тарафыннан алынган.



*«1030 т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

14

343 т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ачык яшькелт төстәге рус кәгазендә. Филигране бар.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Сакланышы уртача.

Форматы: 16,8 x 21.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 x 16,3.

Язу карасы – текст ачык көрән, фасыл исеме ачык кызыл төстә.

Язу почеркы – вак итеп язылган татар тәгъликы.

Һәр битендә ачык кызыл төстәге кара белән ике баганалы рамка-кыса сызылган.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Р.Мәрдановның китапханәгә бүләк итеп биргән кульязмалар һәм иске басма китаплар тупламасыннан. Татарстанның Әгерҗе районы Яңа Аккуҗа авылында яшәүче Лотфия Арслановадан 1990 елда алынган булган.

Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.



*«343 т» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

15

1667 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Сакланышы начар.

Яшькелт-зәңгәр төстәге рус кәгазендә. Филигране бар.

Форматы: 14 х 19.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 х 15,5.

Язу карасы – көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Кәгазьнең читләре тетелгән.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 2000 елның июль аенда Пермь өлкәсенең Барда районы Барда авылы музееннан алынган.


ТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛ...
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА...
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ и РЕДКИХ КНИГ
1667 т

*«1667 т» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

16

1267 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Сакланышы начар.

Начар сыйфатлы саргылт төстәге рус кәгазендә.

Форматы: 17,4 х 22.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 14,5 х 18.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу почеркы – нәсех.

Кәгазе таушалган, бит читендәге язулары уңган.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Китапханәгә тупланган басма китапларның берсе эченнән китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан 2002 елда табып алынган.




*«1267 т» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

## 17

1668 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Сакланышы яхшы.

Яшькелт-зәңгәр төстәге рус кәгазендә. Филигране бар.

Форматы: 16,3 х 20.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10,5 х 15,5.

Язу карасы – караңгы көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Күчерелгән вакыты – XIX гасыр башы.

Китапханәгә Тобольск шәһәре имамы Габделмәҗит хәзрәт 2002 елда бүләк итеп биргән.

Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

3. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).




*«1668 т» шифрлы кулъязма. 1б кәгазь.*

## 18

777 т **قصهٔ يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге рус кәгазендә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Бер бит кәгазьнең дүрттән бер өлеше зурлыгында.

Сакланышы начар. Кәгазь читләре тетелгән.

Форматы: 9 х 11.

Язу карасы – көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгълики.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче чиреге.

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 1996 елның июль аенда Пенза өлкәсенең Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында яшәүче Усман Габдеррәшитовтан алынган.



*«777 т» шифрлы кульъязма. 1а кәгазь.*

19

497 т قصهء یوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Зәңгәр төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 34 кәгазьдә. Башы юк.

Тышлыгының бер (арткы) өлеше сакланган. Ул иске кульязма битләреннән ябыштырып эшләнгән һәм төбе күн белән тупләнгән булган. Тышлыкның кәгазьләре аерылган, читләре ашалып түгәрәкләнгән.

Сакланышы яхшы. Төбе җеп белән тегелгән. 1, 4–6 кәгазьләре җебеннән аерылган.

Форматы: 15,1 x 20,6.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 9,5 x 14,5.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*............................................ йиде,*
*Камулари гъәҗаибә калурлар имди.*

Текстның ахыры (33а кәгазьдә):

*Бу арада бу китабны тәмам кыйлдым,*
*Вә нәфәгъна вә әййакүм кыйла имди.*

Бу кульязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 180 битендәге, ә ахыры 294 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – текст һәм фасыл исемнәре ачык көрән төстәге кара белән язылганнар. Бер фасыл исеме (7б кәгазьдә) кызыл кара белән, ә бер фасыл исеме (31а кәгазьдә) зәңгәр кара белән язылган.

Язу почеркы – нәсех.

Тексттагы кайбер төрки сүзләрдә хәрәкәләр куелган һәм бик еш тәнвиннәр кулланып язылган. Мәсәлән, 1а кәгазьдә «тәңремд(ән)» һәм 17б кәгазьдә «дилд(ән)-күзд(ән)» рәвешендә.

Кустодлары бар, тотрыклы.

31а кәгазендә кызыл төстәге кара белән рамка-кыса сызылган.

1а кәгазьнең уртасы ертылган, өске почмагы кыйгач рәвештә ертылып төшкән.

Филиграньдәге еллары «1805» һәм «1825».



*«497 т» шифрлы кульязма. 31а кәгазь.*

Күчерүчесе – Габдулла бине Батыркәй, мулла Мостафаның улы өчен (исеме язылмаган).

Гади бизәкле рамкага алынган коллофондагы язуы: «Кәтәбәһе фәкыйрь әл-хәкыйрь би бизагъәт Габдулла бине мулла Батыркәй ли-әҗли ибни мулла Мостафа».

Кульязманы Казан шәһәрендә яшәүче шагыйрь Мөхәммәт Садри 1995 елның 5 маенда китапханәгә бүләк итеп биргән. Аның юллама хатында гамәлдәге татар графикасы белән түбәндәгеләр язылган.

Беренче кәгазьдә:

«Бисмиллаһир-рахмани-рахим.

Омск өлкәсе, Тәвриз районы Кип-Куллар авылының 82 яшьлек мәчет карты Юма Абдрашев бүләк иткән бик борынгы китап үрнәге. Юма бабай аны «җиде бабамның кулдан-кулга, озыннан-озынга укый, саклап килгән китабы» диде. Юма бабай үзе «мин Күчем ханның җиденче буыны» диде.

Бу китапны ул миңа 1940 елның 15 июлендә тапшырды. Хәзер бу бабайга 135 яшь булыр иде.

Мөхәммәт Садри.

5 май, 1995 ел. Казан».

Икенче кәгазьдә: «Бисмиллаһир-рахмани-рахим.

Килеп кергәч белем сараена,
Тәңрем, сиңа ашты теләгем.
Шаһит булсын – китапханәбезгә
Минем дә бар икән бүләгем.
Хөр Кол Гали белән бергә яшәп,
Бергә типсен иде йөрәгем.
Изге бәйрәм көннәре мөбарәк булсын!

Мөхәммәт Садри.

5 май, 1995».

Бу кульязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

## 20

779 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ачык яшькелт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 69 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы начар. Төбе җеп белән тегелгән. 1–7 нче кәгазьләре җебеннән аерылган.

Форматы: 17,2 х 21,3.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 14 х 16,5 (17).

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Монлар әйдүр бу эше кыйлмаймуз...*

Текстның ахыры (69а кәгазьдә):

*Йосыф сәүчи къиссасен белүр ирсәң,*
*Нитәлекен безә мәгълүм [кылгыл имди].*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 96 битендәге, ә ахыры 426 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – текст һәм фасыл исемнәрендә ачык көрән төстә. Бары тик бер генә фасыл исеме (29б кәгазьдә) кызыл кара белән язылган.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Тексттагы кайбер төрки сүзләрдә хәрәкәләр куеп һәм тәнвиннәр кулланып язылган. Мәсәлән, 58а кәгазьдә «хакд(ан)» һәм 61а кәгазьдә «иленд(ән)» рәвешендә.

Кустодлары кәгазь битенең ике ягы өчен дә тотрыклы рәвештә бирелгән.

Кулъязма элек тулаем юешләнгән булуы сәбәпле, язулары уңган. Һәр битенең уртасыннан түбәнге өлешендәге язулары начар күренә. 11 нче кәгазьнең өске өлеше ертылган. 62–68 кәгазьләр бер-берсенә ябышканнар. 68б һәм 69 кәгазьләрдәге язулар бөтенләй күренми, укырлык түгел.

Филиграньдәге еллары «1825» һәм «1826».

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пенза өлкәсенең Неверкино районы Биги авылында яшәүче Мөнирә Акчуринадан 1996 елның июль аенда алынган.



*«779 т» шифрлы кулъязма. 10а кәгазь.*

## 21

486 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Кулъязманың 1–47 кәгазьләре саргылт төстәге һәм 48–78 кәгазьләре яшькелт-зәңгәр төстәге рус кәгазьләрендә. Ак кәгазьдә филиграньнәре юк, ә яшькелт-зәңгәрендә бар.

Күләме: 76 кәгазьдә. Башы һәм ахыры бар.

Тышлыгы – 1991–1995 еллар арасында катыргы һәм яшел дермантин белән тышланган.

Сакланышы уртача.

Форматы: 16 х 20,3.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 1–3 кәгазьләрдә 11,5 (12) х 17; 4–76 нчы кәгазьләрдә 10 (10,5) х 14,5 (15).

Текстның башы (1б кәгазьдә):

*Хәмде сәна, шөкер сипас ул Әхәдә,*
*Мөлкәтенең зәвале йук ул Самәдә.*

Текстның ахыры (76б кәгазьдә):

*Бу арада бу китабны тәмам кыйлдум,*
*Вә нәфәгъна вә әййакум кыйлар имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 46 битендәге, ә ахыры 294 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – ачык һәм караңгы көрән төстә. Фасыл исемнәре, 41б кәгазьдә әсәрнең төп текстында булмаган гарәп телендәге ике юллык Коръән сүзләре һәм 73б кәгазьдә шигъри юлның бер өлеше кызыл кара белән язылган.

Язу почеркы – 1б–3б кәгазьләрдә эре язулы татар тәгъликы; калган кәгазьләрдә тотрыксыз рәвештә өлешчә нәсех һәм күпчелеге татар тәгъликы белән язылган. Бер үк биттә текст берничә төр (тәгъликъ, нәсех) белән язылган урыннары бар. Мәсәлән, 7б, 10а, 32б, 54б, 58б, 59а кәгазьләр.

Кайбер битләрдә (мәсәлән, 33а, 33б, 39б, 50б, 54а кәгазьләрдә) шигъри юлларның ахырларын тутырып язу өчен өстәмә билгеләр һәм сызыклар өстәп яки ахыргы хәрефләре сузынкы итеп, бизәк-



*«486 т» шифрлы кулъязма. 3б кәгазь.*



*«486 т» шифрлы кульязма. 19а кәгазь.*

ләбрәк һәм калынайтып язылган. Текстта тәнвиннәр куллану күзәтелә (мәсәлән, 69б кәгазьдә һ.б.).

Кульъязманың 1б–3б кәгазьләре җыентыкның төп өлешеннән кәгазенең төре, язуы һәм текст мәйданының зурлыгы белән аерылып тора. Бу өч кәгазьнең юешләнгәннән калган эзләре дә башка кәгазьләрдә юк. Шулай ук бу кульъязманың 3 нче һәм 4 нче кәгазьләре арасында, әсәрнең төп тексты белән чагыштырып караганда, 16 юллык өзеклек бар. Кульъязманың, бигрәк тә башындагы өлешендә (мәсәлән, 4–7 кәгазьләрдә), таушалган кәгазь битләренең читләре өстәмә кәгазьләр ябыштырылып XIX гасырда реставрацияләнгән. Язулары уңган һәм өстәмә кәгазь белән капланган урыннары яңартылып язылган. Китапны төпләп тышлаганда (1991–1995 елларда) бүтән битләре дә реставрацияләнгән. Югарыда саналган үзенчәлекләрне исәпкә алганда, кульъязманың башындагы өч кәгазе төп өлешенә соңгырак дәвердә генә кушылган дигән нәтиҗәгә килдек. Әгәр ул өлеше XIX гасырда яисә XX гасыр башларында өстәлгән булса, кыйссаның җуелган юллары, һичшиксез, өстәп язылыр иде.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Кульъязманың 1а, 7а, 78б кәгазьләрендә «Кильдиев Марат Виль улы» дигән штамп сугылган.

Филиграньдәге елы «1827».

Коллофоны «Тәммәт ә[л]-китаб би-гауни Аллаһ мөликел-ваһаб вә иләйһи мәрҗәга вәл-мәэаб. Тәммәт тәмам булды».

Китап хуҗаларының язмалары түбәндәгечә:

1) XIX гасырга караган язулар (1а кәгазьдә): «Әүвәл алдым бер такта чәй, 1 сум 5 тиен... Әүвәл Әхмәд 18.. нче йылда, нуябер. Йәнә Әхмәд... Йәнә Сафиулла. Әүвәл алдым ун баш төлке тиресе – бәһасе булды кырык сум көмеш.

Ошбу китаб ийәсе
Йәшел чапан кийәсе.
Укыб сабагын белмәсә,
Күтенә күшәкә тийәсе».



*«486 т» шифрлы кульязма. 26б кәгазь.*

2) М.Килдиев язулары.

1а кәгазьдә: «Шедевр Золото-Ордынской культуры. Соч. Али о Йосифе Прекрасном из классики татарской литературы XIII в., список относится ко II пол. XIX в. Поволжье.

Кильдеевский список. Был найден Кильдеевым Маратом в Казанской соборной мечети имени Шигапа Марджани 14 августа в 1991 году. В настоящее время составляет ценность личного архива Кильдеева Марата Вил угълы. В случае его смерти или утери незамедлительно нашедшему передать эту книгу в отдел рукописей И.Я.Л.И. по улице Ленина г. Казани Ахметзянову Марселю Ибрагимовичу лично!

7а кәгазьдә (гарәп хәрефләре белән): «Ошбу китабның ийәсе Килдиев Маратдыр, һәза китаб Казандагы Шиһаб Мәрҗани җәмигындән 14 нче аугустда 1991 нче сәнәдә табыб алынмыш иде».

Кулъязманың 76б–78 кәгазьләрендә татар телендә иман мәгънәсе һәм гарәп телендә намаз шартлары турындагы текстлар язылган.

Китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Марат Килдиевтән 1995 елның февраль аенда сатып алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Каталог выставки «Литературное наследие татарского народа». Из фондов Российской национальной библиотеки (г.Санкт-Петербург) и Национальной библиотеки Республики Татарстан (г.Казань), г.Казань, 30. 08 – 30. 09. 2001 г. – С. 14.

## 22

1782 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

1–7 кәгазьләре ак төстәге, 8–19 кәгазьләре зәңгәрсу ак төстәге, 20–21 кәгазьләре зәңгәр төстәге рус кәгазендә язылган. Филиграньнәре бар.

Күләме: 21 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача. Төбе җеп белән тегелгән. Яртысыннан күбрәк өлеше тегелгән җебеннән аерылган.

Форматы: 17 (17,4) х 21,6 (22; 22,4).

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 (12,5) х 15,5 (16).

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Һич иксәксез утур өч мең ирәнләрә,*
*Барчасына мөкътәда булам имди.*

Текстның ахыры (21б кәгазьдә):

*Бу гәз мәдәд диләрмән сәндән нигә,*
*Бу угъланны бәңа мотигъ кыйлгыл имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 48 битендәге, ә ахыры 148 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – караңгы һәм ачык көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Текстта хәрәкәләр һәм тәнвиннәр күп кулланылган. Мәсәлән, 1а кәгазьдә берничә юл тулаем хәрәкәләр белән язылган, 3а кәгазьдә «дөш(ин)», 3б кәгазьдә «безд(ән)», 7а кәгазьдә «шәфәгъәт(ин)», 19 б кәгазьдә «үз(ин)», «хөрмәт(ин)» рәвешләрендәге тәнвиннәр белән язылган.

Кустодлары бар, тотрыклы.

15б кәгазе таушалган, 17–18 кәгазьләренең читләре ертылган.

Филиграньдәге елы «1829».

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Пермь өлкәсенең Барда районы Үдик (Елпачиха) авылында яшәүче Рәүфә Адутовадан 2001 елның июль аенда алынган.



*«1782 т» шифрлы кулъязма. 11а кәгазь.*

## 23

2068 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 72 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача. Төбе җеп белән тегелгән.

Форматы: 18 х 22.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 х 15 (15,5).

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Тугар күн, тулан ай, унбер йылдыз,*
*Дөшүм эчрә сәҗдә кыйлды бәңа дүб-дүз.*

Текстның ахыры (7б кәгазьдә):

*[Әгәр сән] хакъ рәсүл улур ирсәң,*
*Рисаләт дәгъвасы кыйлур ирсәң.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 52 битендәге, ә ахыры 426 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – ачык һәм караңгы көрән.

Язу почеркы – нәсех.

Текст тәнвиннәр кулланылып язылган. Мәсәлән, 58а кәгазьдә «къәрдәшләр(ин)», «алдукълар(ин), «салдукълар(ин)» рәвешендә.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Кәгазь битләрендә юешләнүдән калган таплар бар.

Филиграньдәге еллары «1831» һәм «1832».

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 2006 елның июль аенда Чуашстан Республикасының Комсомол районы Урмай авылында яшәүче Илшат Фәтхуллиннан алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Гобәйдуллин Л. Тарихыбыз эзләреннән // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2006. – № 2. – Б. 27–29.



58

یهودا ایدور آنی بر کورا ... اول بلارو کی نه ایمش بز بیلا ...
قدر بلیب سنکا اوچون سقلا یالم بیلارو کی یهودا یا ویرور ایدی
یهودا آلدی کورک سرچه دیدی کندو زنک قولنه اونا قویدی
دا ذیل اسباب یهودادان آلوحدی کرو ابنا یابنا قولنه کیرور ایدی
ابنا یابنا را ذیل صنو ویرو ی روایل آلدی قولنه اورا قویدی
بو عجب ور آنداغی سلو حدی کیرو ابنا یابنا قولنه کلور ایدی
قصه دور قرداشلاری جمله آلدی ابنا یابنا قولنه کرو سلدی
کمسه نک قولنه آنکلا نماد ی ابنا یابنا قولنه کرور ایدی

فصل یوسف عم قرداشلارا اوندا کان

یوسف بیو زدی بنالر جان کلتور بر محکم سرای یکساک بنا قیلسون
اول سرای اوروللوقی قرق آرشون اولسون هم یکساکی قرقی آرشون قیلسون ایدی
بر اسنلار آنده یعقوب صورتنی هم بر اسونلار جمله اوغلانلارنی
هم یوسف بونلارنه قیلدوغنی جمله سنی آنده مکتوب قیلورلار ایدی
آندا یوبا آتاسندا آلدوقلاری طونینی سیوب قیوبه سالدوقلاری
اولدور حکا حقیقت تصدق قلدوقلاری جمله سنی اول دوارا یزارلر ایدی
قیودا جقارمغه کلدوکلاری قولو مرتیب بلانیچی تیب بلساتدوقلاری

*«2068 т» шифрлы кулъязма. 58а кәгазь.*

24

778 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: 7 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача.

Форматы: 17 x 21,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 10 (10,5) x 16.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Йосыф әйде: «Ходавәндә гафур-рахман,*
*Котулмага булмадум һәргиз дәрман».*

Текстның ахыры (7б кәгазьдә):

*Үзүңез аңа эш кыйлмыш такәте так,*
*Сәнең йөзүңез күрмәгә йаулак моштак.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 168 битендәге, ә ахыры 190 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – текст ачык көрән, ә фасыл исеме кызыл төстә.

Язу почеркы – тәгъликъ.

Текстта «уау» хәрефе өстендә өчәр нокта куеп һәм тәнвиннәр кулланып язылган. Мәсәлән, 2б кәгазьдә «тануклык(ин)» рәвешендә.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Кәгазь битләренең читләре таушалган.

Филиграньдә елы «1833».

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 1996 елның июль аенда Пенза өлкәсенең Каменка районы Теләтен авылында яшәүче Рәхимә Раковадан алынган.



*«778 т» шифрлы кульязма. 4а кәгазь.*

25

342 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге рус кәгазендә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент. Бер бит кәгазьнең дүрттән бер өлеше (өске ягы) зурлыгында.

Сакланышы уртача.

Форматы: 7,5 x 17,5.

Язу карасы – көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның икенче чиреге.

Татарстанның Апас районы Кече Кайбыч авылында 1992 елда китапханә хезмәткәре Илгиз Галләмов тарафыннан табылган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.



*«342 т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

26

589 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге рус кәгазендә.

Күләме: 8 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача.

Форматы: 17,5 x 22,3.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 x 17.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Анлар әйдер: «Йа, баба, чук алар адук,*
*Унуламез ул ара дил чук истәдек».*

Текстның ахыры (8б кәгазьдә):

*Андан соңра Йосыф хөкме улды фәрман,*
*Олуг мәнсаб бирде...*
*Һич кемсәнә чыкмаз улды тәдбирендин,*
*Малик...*

Бу кульъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 82 битендәге, ә ахыры 108 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – текст һәм фасыл башлары бер төрле үк – ачык көрән төстә.

Язу почеркы – тотрыксыз татар тәгъликы.

Кустодлар бар, тотрыклы.

7 һәм 8 нче кәгазьләре шактый таушалган. 7а һәм 8б кәгазьләрдә язулары начар күренә.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның икенче чиреге.

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 1995 елның июль аенда Башкортстанның Тәтешле районы Аксәет авылында яшәүче Тимергаян Әхмәтовтан алынган.



*«589 т» шифрлы кулъязма. 3б кәгазь.*

## 27

411 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Аксыл һәм өлешчә ачык яшькелт төстәге рус кәгазендә.

Күләме: 32 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача. Төбе калын җеп белән тегелгән. Ахыргы кәгазе җебеннән аерылган.

Форматы: 17 х 21,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 12 х 16.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Равилләрдән бу ривайәт илә имеш,*
*Корга бине Талут аңа дирләр имеш.*

Текстның ахыры (31б кәгазьдә):

*Бикенде кәнду үзенә вазир кылды,*
*Һәмандәм мөэмин-мөхлис улур имди.*

Бу кульязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 124 битендәге, ә ахыры 208 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – ачык көрән төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Кульязма юешләнү кичергән. 1–3 кәгазьләрнең уң як аскы почмаклары тетелгән (ертык). Битләре пычрак һәм текстка бәйләнешсез язулар белән чуарланган.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның икенче чиреге.

Кульязманың 25а кәгазендә «Ошбу китаб мин мулла Габделкәрим угылы Шәрәфеддин» һәм 29 б кәгазьдә «Ошбу хат йазгучы мин мулла Шәрәфетдин торур. Габдрахман угылы торур» дигән язулар бар.

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 1993 елның июль аенда Пенза өлкәсенең Городище районы Югары Әләзән авылында яшәүче Дәүләтша Мекаевтан алынган.



*«411 т» шифрлы кульязма. 10а кәгазь.*

28

1568 т **قصهء يوسف**

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге рус кәгазендә.

Күләме: Бер кәгазь битенең чирек өлеше зурлыгындагы фрагмент. Ягъни, тулы биттә икешәр багана итеп язылган текстның бер баганасы тарафы.

Сакланышы начар.

Форматы: 8 х 11,5.

Язу карасы – кара төстә.

Язу почеркы – татар тәгъликы.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 2000 елның июль аенда Пермь өлкәсе Барда районының Барда авылы мәчетеннән алынган.



*«1568 т» шифрлы кульязма. 1а кәгазь.*

29

2067 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге рус кәгазендә.

Күләме: 1 кәгазьдәге фрагмент.

Сакланышы уртача.

Форматы: 17,5 х 22.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 14 х 17 (17,5).

Язу карасы – текст һәм фасыл исеме ачык көрән төстә.

Язу почеркы – бозык нәсех.

Бит читләре таушалган, кәгазе таплы.

Күчерелгән вакыты – XIX гасырның беренче яртысы.

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 2005 елның июль аенда Мари Эль Республикасы Бәрәңге районының Хәсән авылында яшәүче Саимә Һидиятовадан.




*«2067 т» шифрлы кулъязма. 1а кәгазь.*

30

404 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Саргылт төстәге рус кәгазендә. Филиграньнәре бар.

Күләме: кулъязма җыентыкның 1–58 кәгазьләрендә. Башы юк.

Сакланышы уртача. Төбе җеп белән тегелгән.

Форматы: 17 х 22.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 х 15.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Дәрмандәләр дәстгире Мәлик-Рахман,*
*Фазле ...*

Текстның ахыры (58б кәгазьдә):

*Аны дәхи ушал йирдә дәфен кыйлды,*
*Зийарәтә бу көн анда варырлар имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 76 битендәге, ә ахыры 290 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – төп тексты караңгы көрән, фасыл исемнәре кызыл төстә. Шулай ук кайбер фасылларның бәйтләре (мәсәлән, 17а, 58а кәгазьләр) һәм аерым юллары (мәсәлән, 19б кәгазь) кызыл кара белән язылган.

Язу почеркы – гади татар тәгъликы.

Кустодлары бар, тотрыклы.

Кулъязманың элек юешләнгәннән калган таплары бар. 1 нче кәгазенең өчтән бер өлеше ертылган.

Күчерелгән вакыты – 1841 ел.

Күчерелгән урыны – Нижний [Новгород] шәһәре.

Күчерүчесе – Юныс бине Фәхретдин бине Байтимер бине Биктимер.

Коллофоны «Кадь вәкъәга әл-фирагъ мин күтүби һәзиһин-нөсхәти әш-шәрифәти әл-мүсәммә Йосыф гамь фи вакъти дүшәнбә фид-дөха. Кятибеһе вә маликеһе Йуныс бине Фәхретдин бине Байтимер бине Биктимер бине фәлан бине фәлан. Моны йазганда кыш иде, каләмем камыш. Гаепләмәгез сез муллалар, каләмем камыш иде. Шәһре Нижнида 1841 нче йылда».



*«404 т» шифрлы кульязма. 40а кәгазь.*

Кулъязма җыентыкның 60б–72а кәгазьләрендә шул ук күчерүче тарафыннан төрки-татар телендәге шигъри дини әсәрнең тулы тексты, 73а–83а кәгазьләрендә «Кыйссаи Әхтәм», 83б кәгазьдә Габделҗәббар Кандалыйның «Сахибҗәмал» поэмасының фрагмент-өзеге һәм 84б–144а кәгазьләрдә «Китабе имам Хөсәен» исемендәге төрки-татарча хикәятләр язылган.

Казан шәһәрендә шагыйрә Заһидә Бурнашева туганнарыннан 1994 елның ноябрь аенда китапханә хезмәткәрләре Р.Мәрданов һәм И.Һадиев тарафыннан алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

## 31

600 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге рус кәгазендә.

Җыентыкның 4б–5б кәгазьләрендәге бу кульязма битләр басма (Казан, 1852) китапның төшкән 3-4 битләре урынына тулыландырып язылганнар.

Сакланышы яхшы. Җыентыкның җеп белән тегелгән төбе урталай ике өлешкә аерылган. Ахыргы (104 һәм 105 нче) кәгазьләре җебеннән аерылган.

Форматы: 13,5 х 21,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11 х 16,5 (17,5).

Текстның башы (4б кәгазьдә):

*Әлхәмде шөкер вә сипас ул Әхәдә,*
*Милке даим би зәваль ул Самәдә.*

Текстның ахыры (5б кәгазьдә):

*Вәләкин әманәтдер җаным угълы,*
*Дустыңны һич кемсәгә сән әйтмәгъел.*

Язу карасы – ачык көрән, 5б кәгазьдәге фасыл исеме (Йосыф галәйһиссәлам дөше) кызыл төстәге кара белән язылган.

Язу почеркы – нәсех.

Кустодлары бар.

Күчерелгән вакыты – [1856-57 еллар].

Күчерүчесе – Мөхәммәтгали Чокрый.

Басма китаплар һәм кульязмалар бергә тупланган бу җыентыкта түбәндәгеләр бар:

1. *Кульязма.* 2б-3б кәгазьләрдә. Шигырьләр. Мөхәммәтгали Чокрый тарафыннан 1858 елда Әстерханда язылган.

2. *Басма китап.* 2б–48б кәгазьләрдә. [Китабе Кыйссаи хәзрәти Йосыф ән-нәби галәйһиссәлам]. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1852. – 88 б.

Китапның башындагы төшкән 2–4 битләре шагыйрь Гали Чокрый тарафыннан кулдан язып тулыландырылган.



بسم الله الرحمن الرحیم

الحمد شکر وسپاسی اول احده — ملکی دایم بی زوال اول صمده
ملکت ایچره بلا شریک اول احده — آنی باقی ذا الجلال بلدک ایمدی
آندین صونکره آننگ دوستی محمده — پیغمبرلر کزیده سی اول احمده
قاب قوسین مقاملی اول احمده — آننگ اوزره تسلیم درود اولسون ایمدی
آندین صونکره اول صدیق صاحب غار — غار ایچنده مصطفی نی توتدی اول یار
یار اولماغه خاطر کلدی دوتمدی غار — آننگ صدقی قمولاردن ارتق ایمدی
آندین صونکره دخی عمر خطاب اوغلی — عالم ایچره مشهور ایردی آننگ عدلی
یوز بنکی ایردین آرتوق ایردی آننگ — توردت بلک تورت یوز مسجد بنا قیلمش
آندین صونکره ازکی عثمان شهیدی وار — آننگ وصفین قرآن ایچره اوکلدی جبار
زهی دقت عطا ویرمشی آنکا غفار — جمیع قرآن خطاسزین درمش ایمدی
آندین صونکره حشم کیر علی کرار — یوز بنک هم ... عسکر اوزره سیاستلر
مشهور که لا سیف الا ذو الفقار — لا فتی الا علی کرار ایمدی
آننگ کونکلی دشمنی ایدی ایکی یکیت — دین مروت ایکیلاسی ایکی شهید
برسی حسن برسی حسین ایکی شهید — شبان اهل جنت آنلار دیرلر ایمدی
آندین صونکره خلفاء راشدین لره — علماء شهداء تابعین لره
اولیاء واتقیاء همه دین لره — جمله سندین خالق راضی اولسون ایمدی
آندین صونکره اول بختیار ایرانلره — حق حبیبی مصطفی نی کورانلره
هیچ ایکسکسز اوتوز اوچ منک ایرانلره — بارچه سن مقتدا بلا لوم ایمدی
آندین صونکره برایر قوم همشی علم کانی — آننگ برله متزین بو اسلام دینی

ظاهر

*«600 т» шифрлы кульязма. 4б кәгазь.*

3. *Басма китап.* 49а–71б кәгазьләрдә. Вафаи. Китабе мөстәтаб Раунакыль-ислам. – Казан.

Ахырындагы төшкән бите (бер кәгазь) Гали Чокрый тарафыннан язып тулыландырылган.

4. *Кулъязма.* 72 нче кәгазьдә. «Бөре өязе Ирәкте илендә Чокыр авылында указной мулла Мөхәммәдгали Мөхәммәдсалих угылына» Вәрәшбаш авылыннан Камалетдин Мифтахетдин улы 1869 елның 3 февралендә язган хат.

5. *Кулъязма.* 73б–74 кәгазьләрдә. Шигырьләр һәм хикәятләр.

6. *Кулъязма.* 73а, 75а–79б һәм 104а кәгазьләрдә. Хронологик һәм календарь язмалары. Фи бәйане йыл.

7. *Кулъязма.* 80б–90б кәгазьләрдә. Хәдисләр.

8. *Кулъязма.* 91б–92а кәгазьләрдә. Шигырь. Авторы – Шәмсетдин.

9. *Кулъязма.* 91а кәгазьдә. Газалиның «Касыйдәи бөрдә» әсәре өзеге.

10. *Басма.* 92а–103а кәгазьләрдә. Бакыргани Сөләйман. Хәким ата китабы. – Казан, 1849. – 23 б.

Китап хуҗасының язмасы (3б кәгазьдә): «Тәммә нәкъәлә һәзиһир-рисаләти фи йәдил-фәкъир әл-хәкъир Мөхәммәдгъәли Чокрый тәзкирәтән минһү ли-мән хаһ шәфкъәти къәлби фи сәнәти Хаҗитархан мин-әл-бәхрийәти вә фи сәнә 1858 минһүл-мәсихийәти».

Татарстан Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 1995 елның июль аенда Башкортстанның Тәтешле районы Иске Күрдем авылында яшәүче Заһид Галишановтан алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Каталог выставки «Литературное наследие татарского народа». Из фондов Российской национальной библиотеки (г.Санкт-Петербург) и Национальной библиотеки Республики Татарстан (г.Казань). г.Казань, 30. 08 – 30. 09. 2001 г. – С. 15.

4. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.

5. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

32

373 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Юл-юл сызыклы мәктәп дәфтәре битләрендә.

Күләме: 5 кәгазьдә. Башы һәм ахыры юк.

Сакланышы уртача.

Форматы: 17 х 20,3.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 16 х 19,5.

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Монлар әйдер: «Бу эше без кылмайуз,*
*Кулымыза кәлә-комаш алмайурыз».*

Текстның ахыры (5б кәгазьдә):

*Калдырыб халыкка дога кыйлды,*
*Фазлең берлә миңа пәрдә виргел имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 96 битендәге, ә ахыры 116 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – шәмәхә һәм ахырында (5б кәгазьдә) яшел төстә.

Язу почеркы – нәсех.

Текстта совет чорындагы имля үзенчәлекләре бар. Мәсәлән, яңача шәкелдәге «ө» һәм сүз уртасындагы «ы, э» хәрефләре.

Һәр биттәге шигъри ике баганаНЫ аерып тора торган вертикаль рәвештәге параллель икешәр сызык сызылган.

Күчерелгән вакыты – 1950 нче еллар.

Татарстанның Ютазы районы Бәйрәкә авылында яшәүче Әнвәр Яхиннан 1991 елның июнь аенда китапханә хезмәткәре Р.Мәрданов тарафыннан алынган.

Бу кулъязма турында мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. «Йосыф китабы»ның көен көйләп... // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 1999. – № 1. – Б. 26.

2. Марданов Р. Драгоценные находки // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 82.

3. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – № 1. – Б. 15.

4. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 126.



*«373 т» шифрлы кулъязма. 4а кәгазь.*

## 33

1791 т قصهء يوسف

Авторы – Кол Гали.

«Кыйссаи Йосыф».

Ак төстәге совет чоры кәгазе.

Күләме: 4 кәгазьдә. Кәгазьнең бер ягына бер багана рәвешендә язылган. Башы юк.

Сакланышы яхшы. Тегелмәгән аерым кәгазьләрдә.

Форматы: 18 х 20,5.

Бер биттә текст язылган мәйдан: 11,5 (13) х 17,5 (19).

Текстның башы (1а кәгазьдә):

*Кяферләргә һәргиз куңшы улмайамән,*
*Кяферләрдән айру турмак кэрәк имди.*

Текстның ахыры (4а кәгазьдә):

*Аны дәхи ушал йирдә дәфен кыйлды,*
*Зийарәтә бу көн анда варырлар имди.*

Бу кулъязмадагы текстның башы әсәрнең 1983 елгы басмасының 284 битендәге, ә ахыры 290 битендәге текстка туры килә.

Язу карасы – кара төстәге тушь.

Язу почеркы – эре итеп язылган нәсех.

Һәр битенә карандаш белән бит саннары (96–99) куелган.

Күчерелгән вакыты – 1960 нчы еллар.

Күчерелгән урыны – [Казан].

Күчерүчесе – [Альберт Фәтхи].

Казан шәһәрендә яшәгән археограф галим Альберт Фәтхи туганнарыннан 1992 елда алынган.




*«1791 т» шифрлы кульязма. 2а кәгазь.*

## ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ


Абдрашев Юма – № 19
Адутова Рәүфә – № 22
Акчурина Мөнирә – № 20
Арсланова Лотфия – № 14
Ахметзянов Марсель Ибрагимович – № 21

Әхмәд – № 21
Әхмәтов Тимергаян – № 26

Бакыргани Сөләйман – № 31
Бибифатыйма Габделҗәббар кызы – № 11
Биктимерова Нурдидә – № 4
Бурнашева Зәһидә – № 30

Вафаи – № 31

Габделвахид Габделкәрим угылы – № 9
Габделгалләм – № 7
Габделҗәббар Габделмәннаф угылы – № 11
Габделмәҗит хәзрәт – № 17
Габдеррафигъ Габделвахид угылы – № 9
Габдеррәшитов Усман – № 18
Габдрахманова Зарифа – № 11
Габдулла бине мулла Батыркәй – № 19
Габдулла ибне Дауд ибне Ишм[өхәммәд] ибне Динмө[хәммәд] ибне Бикмөхәммәд ибне Кодаш – № 10
Газали – № 31
Галишанов Зәһид – № 31
Галләмов Илгиз – № 25

Зәһидуллин Айрат – №№ 3, 6, 7

Ильяс – № 9

Камалетдин Мифтахетдин улы – № 31
Кандалый Габделҗәббар – № 30
Килдиев Марат Вил улы – № 21
Кол Гали – №№ 1–33

Күчем хан – № 19

Мәрданов Раиф – №№ 1, 2, 8–11, 13, 14, 16,  30, 32
Мекаев Дәүләтша – № 27
Миңнезакир Кәмаледдинев угылы – № 10
Мостафа мулла – № 19
Мөхәррәм – № 9

Нәбиуллина Гөлбикә – № 7

Ракова Рәхимә – № 24

Садри Мөхәммәт – № 19
Сафиулла – № 21
Сәедкол – № 5
Сәйфуллин Нәбиулла – № 4

Таҗетдин – № 9

Фәтхи Альберт – № 33
Фәтхуллин Илшат – № 23

Һидиятова Саимә – № 29
Һадиев Ирек – №№ 1, 2, 8, 13, 30

Чокрый Мөхәммәтгали мулла Мөхәммәдсалих угылы – № 31

Шәмсетдин – № 31
Шәрәфетдин мулла Габделкәрим угылы – № 27
Шәрәфетдин мулла Габдрахман угылы – № 27
Шәрәфиева Фәйрүзә – №№ 3, 6
Шәрифулла – № 7

Юныс – № 9
Юныс бине Фәхретдин бине Байтимер бине Биктимер – № 30

Яхин Әнвәр – № 32

## ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ


Аксәет авылы – № 26
Апас районы – № 25
Арча районы – №№ 3, 6

Әгерҗе районы – № 14
Әстерхан – № 31

Барда авылы – №№ 15, 28
Барда районы – 15, 22, 28
Башкортстан – №№ 4, 26, 31
Бәйрәкә авылы – № 32
Бәрәңге районы – № 29
Биги авылы – № 20
Бөре өязе – № 31

Вәрәшбаш авылы – № 31

Городище районы – № 27

Динис авылы – № 10

Ирәкте иле – № 31
Иске Күрдем авылы – № 31

Казан – №№ 1, 2, 5, 8, 12, 13, 16, 19, 21, 30, 33
Каменка районы – №№ 24
Кече Кайбыч авылы – № 25
Кип-Куллар авылы – № 19
Комсомол районы – № 23
Кузнецк районы – № 18

Мари Эль Республикасы – № 29

Неверкино районы – № 20
Нижний [Новгород] – № 30

Олуг Кавал авылы – № 5
Омск өлкәсе – № 19

Пенза өлкәсе – №№ 18, 20, 24, 27
Пермь өлкәсе – №№ 15, 22, 28

Самара өлкәсе – № 10
Сәйран авылы – № 4

Татар Кынадысы авылы – № 18
Татарстан – №№ 3, 7, 14, 25, 32
Тәвриз районы – № 19
Тәтешле районы – №№ 26, 31
Теләтен авылында – № 24
Теләче районы – № 7
Тобольск – № 17

Урмай авылы – № 23
Урта Мишә авылы – № 7
Уфа – №№ 4, 9, 11

Үдик (Елпачиха) авылы – № 22

Хаҗитархан – № 31
Хәсән авылы – № 29

Чишмә районы – № 4
Чокыр авылы – № 31
Чуашстан Республикасы – № 23

Шонталы районы – № 10

Югары Әләзән авылы – № 27
Ютазы районы – № 32

Яңа Аккуҗа авылы – № 14
Яңа Кишет авылы – №№ 3, 6

## КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ КҮЧЕРЕЛГӘН ВАКЫТЫ ТАБЛИЦАСЫ

| *күчерелгән вакыты* | *бу китаптагы тасвир номеры* | *китапханәдәге саклану шифры* |
|---|---|---|
| XVII гасыр ахыры | 1<br>2 | 590 т<br>591 т |
| XVIII гасыр башы | 3 | 1401 т |
| 1756 елдан соң | 4 | 1228 т |
| 1795–1799 еллар арасы | 5 | 2069 т |
| XVIII гасыр ахыры | 6 | 1402 т |
| 1801 елдан соң | 7 | 1763 т |
| 1804 елдан соң | 8 | 1121 т |
| 1814 елдан соң | 9 | 1400 т |
| 1815 елдан соң | 10<br>11 | 1859 т<br>1774 т |
| 1821 елдан соң | 12 | 2070 т |
| XIX гасыр башы | 13<br>14<br>15<br>16<br>17 | 1030 т<br>343 т<br>1667 т<br>1267 т<br>1668 т |
| XIX гасырның беренче чиреге | 18 | 777 т |
| 1825 елдан соң | 19 | 497 т |
| 1826 елдан соң | 20 | 779 т |
| 1827 елдан соң | 21 | 486 т |
| 1829 елдан соң | 22 | 1782 т |
| 1832 елдан соң | 23 | 2068 т |
| 1833 елдан соң | 24 | 778 т |
| XIX гасырның икенче чиреге | 25<br>26<br>27 | 342 т<br>589 т<br>411 т |
| XIX гасырның беренче яртысы | 28<br>29 | 1568 т<br>2067 т |
| 1841 ел | 30 | 404 т |
| 1856–1857 еллар | 31 | 600 т |
| 1950 нче еллар | 32 | 373 т |
| 1960 нчы еллар | 33 | 1791 т |

# КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ КИТАПХАНӘГӘ АЛЫНГАН ВАКЫТЛАРЫ ТАБЛИЦАСЫ

| *алынган датасы* | *бу китаптагы тасвир номеры* | *китапханәдәге саклану шифры* |
|---|---|---|
| 1991 ел, июнь | 32 | 373 т |
| 1992 ел, | 25<br>33 | 342 т<br>1791 т |
| 1993 ел, май | 1<br>2 | 590 т<br>591 т |
| 1993 ел, июль | 27 | 411 т |
| 1994 ел | 14 | 343 т |
| 1994 ел, ноябрь | 30 | 404 т |
| 1995 ел, февраль | 21 | 486 т |
| 1995 ел, 5 май | 19 | 497 т |
| 1995 ел, июль | 26<br>31 | 589 т<br>600 т |
| 1996 ел, 26 март | 8<br>13 | 1121 т<br>1030 т |
| 1996 ел, июль | 18<br>20<br>24 | 777 т<br>779 т<br>778 т |
| 1996 ел, август | 3<br>6<br>7 | 1401 т<br>1402 т<br>1763 т |
| 1996 ел, 11 декабрь | 4 | 1228 т |
| 1997 ел, 14 август | 10 | 1859 т |
| 1998 ел, март | 9<br>11 | 1400 т<br>1774 т |
| 2000 ел, июль | 15<br>28 | 1667 т<br>1568 т |
| 2001 ел, июль | 22 | 1782 т |
| 2002 ел | 16<br>17 | 1267 т<br>1668 т |
| 2005 ел, июль | 29 | 2067 т |
| 2006 ел, июль | 23 | 2068 т |
| 2008 ел | 5 | 2069 т |
| 2008 ел | 12 | 2070 т |
| *БАРЛЫГЫ* | *33 кулъязма берәмлек* | |

# РЕЗЮМЕ


Третья книга серии «Татарская археография» представляет собой описание рукописей поэмы Кул Гали «Кысса-и Йусуф», хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан.

Поэма «Кысса-и Йусуф», являющаяся выдающимся средневековым литературным памятником волжских булгар-татар, сохранилась до наших дней в многочисленных рукописных списках. Из года в год обнаруживаются новые списки. По нашим подсчётам, сегодня известны около 270 рукописей «Кысса-и Йусуф».

В фондах Национальной библиотеки Республики Татарстан хранятся 33 списка поэмы Кул Гали. Они были приобретены в 1991–2008 годах сотрудниками Отдела рукописей и редких книг в результате проведённых археографических изысканий, а также во время объединённой научно-археографической экспедиции Национальной библиотеки Республики Татарстан и Казанского государственного университета. Списки поэмы «Кысса-и Йусуф» обнаружены в Казани (одиннадцать рукописей), Уфе (три рукописи), Тобольске, а также в Арском, Апастовском, Агрызском, Тюлячинском и Ютазинском районах Татарстана, в Татышлинском районе Башкортстана, в Бардымском районе Пермской области, в Параньгинском районе Республики Мари Эль, в Комсомольском районе Чувашской Республики, в четырех районах Пензенской области, в Шенталинском районе Самарской области.

Самыми древними рукописями поэмы, представленными в фонде библиотеки, являются два её фрагмента, относящиеся к концу XVII века. Четыре единицы относятся к XVIII веку, большинство же (24 рукописи) датируются первой половиной XIX века. Одна рукопись 1856–57 годов, и две единицы – списки XX века. Последние являются доказательством многовековой письменной традиции поэмы.

Описания рукописей в настоящем издании соответствуют общепринятым правилам. Вместе с тем имеются и некоторые особенности. Например, к указанным начальным и конечным строфам поэмы дополнительно дана информация о соответствии их печатному тексту «Кысса-и Йусуф» 1983 года издания.

Некоторые из описанных здесь рукописей неоднократно выставлялись на тематических и других выставках. Крупнейшей из них являлась, например, выставка «Литературное наследие татарского народа», которая была организована совместно с Российской национальной библиотекой (г.Санкт-Петербург) и Национальной библиотекой Республики Татарстан в городе Казани в августе–сентябре 2001 года.

Кроме описаний рукописей в сборнике представлены обзорная статья, именной, географический и другие указатели. Книга включает в себя и образцы факсимиле рукописей.

ЭЧТӘЛЕК

*Мәрданов Р.* «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендәге кульязма нөсхәләре ........................................ 3

КУЛЪЯЗМАЛАР ТАСВИРЛАМАСЫ ........................................ 12

Исемнәр күрсәткече ........................................ 84

Географик атамалар күрсәткече ........................................ 86

Кульязмаларның күчерелгән вакыты таблицасы ........................................ 88

Кульязмаларның китапханәгә алынган вакытлары таблицасы .............. 89

Резюме ........................................ 90

ОПИСАНИЕ РУКОПИСЕЙ ПОЭМЫ «КЫССА-И ЙУСУФ» КУЛ ГАЛИ, ХРАНЯЩИХСЯ В НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКЕ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

*(на татарском языке)*

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 12. 01. 2009. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ № 255.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 12. 01. 2009. Формат 60х84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ № 255.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники
редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.